ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

# ПРИКАЗ

17.09.2019 г. Казань № 178-од

2019-2020 елларга
«Гаилә архивын тапшыр»
конкурсы турында

Гаилә тарихы аша ил һәм туган як тарихын өйрәнүгә нигезләнеп, яшь буында ватанпәрвәрлек тәрбияләүгә ярдәм итү, туган як тарихы белән кызыксынуны саклап калу һәм арттыру, гаилә кыйммәтләрен һәм буыннар арасында элемтәләрне ныгытуга ярдәм итү, архив материаллары белән эшләүгә җәлеп итү, тарихи һәм туган якны өйрәнү әдәбиятын уку, Татарстан Республикасы Архив фондын кыйммәтле тарихи чыганаклар белән баету максатларында боерык бирәм:

1. 2019 – 2020 елларга «Гаилә архивын тапшыр» конкурсы (алга таба – Конкурс) турында нигезләмәне (кушымта итеп бирелә) расларга.
2. «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенә эш төркемен төзергә, җаваплы башкаручыларны билгеләргә, Конкурсны оештыру һәм үткәрү буенча юл картасын расларга (А.Р. Ибраһимов).
3. Финанс-икътисад бүлегенә Конкурста җиңүчеләргә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 10 июнендәге 395 номерлы карары белән расланган «2016 – 2022 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасында каралган максатчан чаралар исәбеннән акчалата түләүләр башкарырга.
4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Рәис Г.З. Габдрахманова

Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының 2019 елның 17 сентябрендәге 178-од номерлы боерыгы белән
РАСЛАНДЫ

# 2019 – 2020 елларга «Гаилә архивын тапшыр» конкурсы турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә 2019 - 2020 елларга «Гаилә архивын тапшыр» конкурсын (алга таба – конкурс) үткәрү һәм оештыру тәртибен, шартларын, конкурс эшләрен бәяләү критериеларын билгели.

1.2. Конкурсның максатлары: гаилә тарихы аша ил һәм туган як тарихын өйрәнүгә нигезләнеп, яшь буында ватанпәрвәрлек тәрбияләү; туган як тарихы белән кызыксынуны саклап калу һәм арттыру; гаилә кыйммәтләрен һәм буыннар арасында элемтәләрне ныгытуга ярдәм итү; архив материаллары белән эшләүгә, тарихи һәм туган якны өйрәнү әдәбиятын укуга җәлеп итү; Татарстан Республикасы Архив фондын кыйммәтле тарихи чыганаклар белән баету.

1.3. Конкурсны оештыручы – Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты (алга таба – ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты).

1.4. Конкурсны финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 10 июнендәге 395 номерлы карары белән расланган «2016 – 2022 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасында каралган максатчан чаралар хисабына гамәлгә ашырыла.

## II. Конкурста катнашучылар

2.1. Конкурста катнашу бушлай, ирекле рәвештә башкарыла.

2.2. Конкурста гаилә архивлары хуҗалары катнаша.

2.3. Конкурска Татарстан Республикасының барлыкка килүе, үсеше тарихын чагылдыра торган гаилә архивлары кабул ителә.

## III. Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе

3.1. Конкурс читтән торып үткәрелә. Конкурста катнашучыларның эшләре читтән торып 2 этапта карала:

1 этап – муниципаль, 2019 елның 4 ноябреннән алып 2019 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) башкарма комитетларының архив бүлекләре (идарәләре) тарафыннан үткәрелә;

2 этап – республика, 2020 елның 1 маеннан алып 2020 елның 31 маена кадәр үткәрелә.

3.2. Конкурста муниципаль этапта катнашу өчен Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башкарма комитетының архив бүлеге (идарәсе) адресына электрон рәвештә һәм/яисә кулдан-кулга, почта аша гариза бирелә.

3.3. Конкурс документларын тапшыру вакыты: 2019 елның 4 ноябреннән алып 2019 елның 27 декабренә кадәр, шул көннәрне кертеп.

3.4. Конкурста катнашуга тиешле вакыт эчендә тапшырылган, эчтәлеге һәм төзелеше әлеге Нигезләмә таләпләренә туры килә торган конкурс документлары алына.

3.5. Муниципаль этап нәтиҗәләре буенча конкурсның республика этабына Татарстан Республикасы муниципаль районнарыннан бер гаилә архивы, Татарстан Республикасы шәһәр округларыннан дүрт гаилә архивы, Казан шәһәреннән җиде гаилә архивы җибәрелә.

3.6. Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) башкарма комитетларының архив бүлекләре (идарәләре) 2019 елның 31 декабренә кадәр электрон рәвештә konkurs.genealogia@yandex.ru электрон почта адресына һәм / яисә кулдан-кулга, «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» ДБУ) адресына: Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 4 нче йорт, «Гаилә архивын тапшыр» тамгасын куеп, муниципаль этапта җиңүчеләрнең түбәндәгеләрдән гыйбарәт документлар пакетын тапшыралар: конкурста катнашу өчен гариза (1 нче кушымта), шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә, тапшыруга һәм таратуга рөхсәт (2 нче кушымта), шәхси бәяләү кәгазьләре (3 нче кушымта), конкурсның муниципаль этабы жюри утырышы беркетмәсе (4 нче кушымта), шулай ук гаилә архивы документларының электрон күчермәләре *(исемлек буенча)*.

3.7. Конкурста катнашу өчен сайлап алу тәртибе, сроклары, шартлары һәм критериелары турында мәгълүмат, конкурс документларын кабул итә башлаганчы 15 календарь көннән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә ТР Архив эше буенча дәүләт комитетының рәсми сайтына (http://arhiv.tatarstan.ru) (алга таба – ТР Архив эше буенча дәүләт комитетының рәсми сайты) урнаштырыла.

## IV. Конкурсны оештыру комитеты

4.1. Конкурс үткәрү һәм гаилә архивларын сайлап алу өчен Татарстан Республикасының һәр муниципаль районында (шәһәр округында) Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башкарма комитетының архив бүлеге (идарәсе) вәкилләреннән, музей хезмәткәрләреннән, фәнни белгечләрдән жюри функцияләре белән (конкурс эшләрен бәяләү, муниципаль дәрәҗәдә (шәһәр дәрәҗәсендә) катнашучылар рейтингын төзү һәм сайлап алу) район (шәһәр) оештыру комитетлары төзелә.

4.2. Конкурсның республика этабын оештыру, үткәрү һәм йомгак ясау өчен ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты, «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» ДБУ вәкилләреннән республика оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты)

төзелә, оештыру комитеты рәисе, рәисе урынбасары һәм әгъзалары ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты боерыгы белән раслана.

4.3. Оештыру комитеты функцияләре:

конкурсның оештыру эшләре буенча әзерлеген һәм үткәрелүен тәэмин итү;

муниципаль районнар (шәһәр округлары) башкарма комитетларының архив бүлекләре (идарәләре) тарафыннан сайлап алынган конкурс гаризаларын җыю;

массакүләм мәгълүмат чараларында, «Татарстан Республикасы архивлары» порталында һәм ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты сайтында конкурс барышы турында хәбәр итү;

жюри беркетмәсе нигезендә җиңүчеләр исемлеген төзү.

4.4. Әлеге Нигезләмәнең 4.1 һәм 4.2 пунктларында күрсәтелгән оештыру комитетларының эше аларның утырышларында гамәлгә ашырыла. Әгәр аларда оештыру комитетлары әгъзаларының гомуми саныннан күпчелеге катнашса, утырыш хокукка ия дип санала.

## V. Конкурста жюри

5.1. Конкурска бирелгән иң яхшы гаилә архивларына бәя бирү һәм җиңүчеләрне билгеләү максатыннан Конкурс комиссиясе (алга таба – Комиссия) төзелә.

5.2. Комиссиянең персональ составы, республика башкарма хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы иҗтимагый оешмалары, «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» ДБУ вәкилләреннән, фәнни җәмәгатьчелек вәкилләреннән Комиссия рәисе, рәис урынбасары һәм җаваплы секретаре җитәкчелегендәге кимендә 9 кешедән гыйбарәт булып, ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты боерыгы белән раслана.

5.3. Комиссия эше белән рәис җитәкчелек итә. Ул булмаган очракта, аның бурычлары аның урынбасарына йөкләнә. Комиссия өстәмә рәвештә экспертлар җәлеп итү хокукына ия була. Конкурс нәтиҗәләрендә шәхси мәнфәгатьләре булган затлар Комиссия әгъзалары була алмый.

5.4. Комиссия эше аның утырышында башкарыла. Әгәр утырышта әгъзаларның гомуми саныннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, утырыш хокуклы дип санала. Комиссиянең җаваплы секретаре тавыш бирү хокукына ия түгел.

5.5. Комиссия карары утырышта катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа рәислек итүче һәм җаваплы секретарь кул куя. Тавышлар саны тигез булганда, рәис тавышы хәлиткеч була.

5.6. Конкурска бирелгән гаилә архивларын бәяләгәндә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

бәяләү критериеларына нигезләнеп, бирелгән материалларны бәяләүнең объективлыгы;

конфиденциальлек.

5.7. Комиссия әгъзалары һәр критерий буенча баллар куя, һәм алар кушыла. Һәр критерий буенча баллар саны 10 баллы шкала буенча билгеләнә (0 дан алып 10 га кадәр).

Баллар «Индивидуаль бәяләү кәгазьләре»нә кертелә, Комиссия әгъзасы имзасы белән таныклана һәм Комиссия рәисенә тапшырыла (3 нче кушымта).

5.8. Комиссия әгъзалары тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 7 бүлегендә күрсәтелгән критерийлар буенча куелган балларны кушканнан соң, катнашучыларның йомгаклау рейтингы төзелә, ул Комиссия рәисе һәм әгъзалары тарафыннан имзалана.

## VI. Гаилә архивларының эчтәлегенә карата таләпләр

7.1. Эчтәлеккә карата таләпләр:

Конкурста катнашучылар сайлап алу үткәрү өчен түбәндәгеләрне тапшыра:

төп чыганакта үз гаилә архивының фотодокументлары: позитив, негатив, слайдлар, кәгазь позитив (фотография), фотоальбом, пыялада негатив;

төп чыганакта үз гаилә архивының видеодокументлары (видеокассеталар, видеодискалар, флэш туплагыч);

төп чыганакта үз гаилә архивының фонодокументлары (магнит тасма, магнит кассета, оптик диск, флэш туплагыч)

тәкъдим ителгән фото -, фоно -, видеодокументларга аннотацияләр;

гаиләнең кыскача тарихы, гаилә әгъзаларының, шул исәптән хезмәт ветераннарының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның иҗтимагый һәм һөнәри эшчәнлеге турында мәгълүматлар.

7.2. Эшләр татар һәм (яки) рус телләрендә тапшырыла.

## VIII. Бәяләү критериелары

8.1. Бәяләү критериелары:

конкурсның максатларына һәм бурычларына туры килү (0 алып 10 баллга кадәр);

архив документларының тулылыгы һәм мәгълүмати байлыгы (0 алып 10 баллга кадәр);

гаилә документларында Татарстан оешуның, аның үсешенең төп чорлары чагылу дәрәҗәсе (0 алып 10 баллга кадәр);

архив документларының физик торышы (0 алып 10 баллга кадәр);

конкурска тәкъдим ителгән документларның төрлелеге (шул исәптән фото, видео, фонодокументлар) (0 алып 10 баллга кадәр).

## IX. Җиңүчеләрне билгеләү, нәтиҗәләр чыгару һәм җиңүчеләрне бүләкләү тәртибе

9.1. Документлар пакеты тапшырылганнан соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча Комиссия утырышы үткәрелә.

9.2. Конкурста җиңүчеләр исемлеге катнашучыларның йомгак рейтингы нигезендә төзелә.

9.3. Конкурста җиңүчеләр дип рейтингта беренче өч урынны алган катнашучылар танылa.

9.4. Конкурста җиңүчеләр исемлеге ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән, Комиссиянең йомгаклау утырышы беркетмәсенә нигезләнеп, беркетмәгә кул куелган көннән алып 3 эш көненнән дә соңга калмыйча раслана.

9.5. Конкурста җиңүчеләр исемлекләре боерыкка кул куелган көннән алып 3 эш көне эчендә ТР Архив эше буенча дәүләт архивының рәсми сайтына урнаштырыла.

9.7. Конкурста җиңүчеләр түбәндәгечә бүләкләнә:

конкурс дипломнары һәм түбәндәге күләмдәге акчалата премияләр белән:

I урын өчен – 50 000 (илле) мең сум

II урын өчен – 30 000 (утыз) мең сум

III урын өчен – 20 000 (егерме) мең сум.

Конкурста җиңүчегә түләнергә тиешле сумма Татарстан Республикасы бюджетына салым, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр күләменә киметелә.

9.8. Конкурста катнашучылар тапшырыла торган документларның дөреслеген, шулай ук тапшырыла торган материалларны төзегәндә өченче затларның авторлык һәм башка хокуклары бозылмавын гарантияли.

Әлеге шарт бозылган очракта, конкурста җиңүчеләргә бүлеп бирелгән акчалар Татарстан Республикасы бюджетына законнарда билгеләнгән тәртиптә кире кайтарылырга тиеш.

## X. Өстәмә мәгълүмат

10.1. Конкурста җиңгән гаилә архивлары документларының төп нөсхәләре «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» ДБУ саклауга кабул ителә һәм Татарстан Республикасы Архив фонды составына кертелергә тиеш. Документлар архивка килешү нигезендә керә.

10.2. Тәкъдим ителгән документларга авторлык хокуклары конкурста катнашучыларда кала.

10.3. Конкурсны оештыручы архив чараларын таныту максатларында, мәгълүмат һәм презентация материалларын ясау өчен конкурс эшләрен, шул исәптән конкурска гаризаларга беркетеп җибәрелгән фотоларны, видеороликларны һәм башка документларны авторлык хокукларын саклап куллану хокукын үзендә калдыра.

10.3. Җиңүчеләр исемлегенә кермәгән конкурста катнашучыларның барысына да конкурста катнашучылар сертификатлары бирелә, алар җиңүчеләр исемлеге урнаштырылганнан соң 10 эш көне эчендә катнашучының E-mail адресына электрон рәвештә җибәрелә.

2019 - 2020 елларга
«Гаилә архивын тапшыр»
конкурсы турында
нигезләмәгә
1 нче кушымта

«Гаилә архивын тапшыр» конкурсында катнашу өчен
гариза

| | |
|---|---|
| Катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме | |
| Катнашучының, индекс күрсәтелеп, тулы йорт адресы | |
| Катнашучының элемтә өчен телефоннары | |
| Катнашучының E-mail адресы | |

2019 - 2020 елларга
«Гаилә архивын тапшыр»
конкурсы турында
нигезләмәгә
2 нче кушымта

Шәхси мәгълүматларны
эшкәртүгә, тапшыруга һәм таратуга
рөхсәт

Мин ______________________________________________________________
(*ФИАи тулысынча*)
2019 елда «Гаилә архивын тапшыр» конкурсы өчен түбәндәге күләмдә шәхси мәгълүматларымны, «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, эшкәртүгә, тапшыруга һәм таратуга (аларны миннән һәм/яки теләсә кайсы өченче заттан алуны да кертеп) рөхсәт бирәм:

Эшкәртелә торган шәхси мәгълүматлар (ФИАи. (соңгысы – булган очракта) исемлеге , җенес, туу датасы һәм урыны, гражданлык, шәхесне таныклый торган документның реквизитлары (документның төре, сериясе һәм номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән), яшәү урыны, теркәлү урыны, телефон номеры (шул исәптән кәрәзле телефон номеры), электрон почта адресы).

________________________________________________________________________
(*ФИ.Аи. (соңгысы – булган очракта), имза*)

__________________________

(дата)

2019 - 2020 елларга
«Гаилә архивын тапшыр»
конкурсы турында
нигезләмәгә
3 нче кушымта

Индивидуаль бәяләү кәгазьләре

| Гариза бирүченең ФИАи, конкурс эшенең исеме һәм эшне тәкъдим итү форматы | |
|---|---|
| Критерийлар | 0 алып 10 баллга кадәр |
| конкурсның максатларына һәм бурычларына туры килү | |
| архив документларының тулылыгы һәм мәгълүмат ягыннан байлыгы | |
| гаилә документларында Татарстан оешуның, аның үсешенең төп чорлары чагылу дәрәҗәсе | |
| архив документларының физик торышы | |
| конкурска тәкъдим ителгән документларның төрлелеге (шул исәптән фото, видео, фонодокументлар) | |
| БАРЛЫГЫ | |

«___» ___________, 20____ ел ________________________/________________________

Төзелү датасы Жюри әгъзасы имзасы Бәяләмә имзасын аңлатып язу

2019 - 2020 елларга
«Гаилә архивын тапшыр»
конкурсы турында
нигезләмәгә
4 нче кушымта

конкурсның муниципаль этабы жюри утырышлары
БЕРКЕТМӘСЕ

Татарстан Республикасы _______________ муниципаль районы (шәһәр округы)
башкарма комитетының Архив бүлеге (идарәсе)

Архив бүлегенең почта адресы (идарәсе), e-mail_____________________________
(индекс, муниципаль район,
______________________________________________________________________
шәһәр, район, урам, йорт)

Муниципаль архив җитәкчесенең ФИАи (тулысынча), телефон
______________________________________________________________________

Конкурсның муниципаль этабы жюри рәисе ФИАи (тулысынча)
______________________________________________________________________

Утырыш көне ____________________________________________________________

Конкурсның республика этабына гаилә архивы документларын тапшырырга:

______________________________________________________
(Катнашучының исем-фамилиясе)

Жюри әгъзаларының имзалары:
(имза) (ФИАи, вазыйфа)______________________________

(имза) (ФИАи. вазыйфа) ______________________________

(имза) (ФИАи. вазыйфа) ______________________________

Беркетмә расланды______________________________________
(муниципаль этапта жюри рәисе имзасы)